**Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Останково авылы**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«18» ноябрь, 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 47/2 номерлы карары нигезендә, Останково авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. . «2026 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Останково авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

**«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Останково Үзәк урамындагы су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, торбалар урнаштыру, махсус техника хезмәтләре күрсәтү) »**

2. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Останково авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Останково авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Назметдинов